ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГУЛКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗАИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ГУЛКИН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№1** **31.01.2022 ел.**

**"2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм аларны саклау муниципаль программасын раслау турында» 2021 елның 22 октябрендәге 14 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. "2021-2023 елларга Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге җирләреннән файдалану һәм аларны саклау муниципаль программасын раслау турында» 2021 елның 22 октябрендәге 14 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кушымтада 4 бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә:

4. Муниципаль программаның төп чаралары исемлеге

Муниципаль программа кысаларында Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Гулкин авыл җирлеге территориясендә җирләрне саклау һәм алардан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру буенча түбәндәге чаралар планлаштырылган:

| N п\п | Чараның исеме | Финанслау чыганагы | Башкаручы | Башкару сроклары | Җаваплы зат |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Гражданнар җыеннарында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы җир | Җирле бюджет:<br>2021 ел – 100 сум,<br>2022 ел – 100 сум,<br>2023 ел – 100 сум. | Авыл җирлеге башкарма комитеты | 2021-2023 еллар | Башкарма комитет җитәкчесе |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | законнары нормаларын аңлату | | | | |
| 2. | Авыл хуҗалыгы җирләрен агачлар һәм куаклар, чүп үләннәре басып китүдән саклау буенча чаралар күрү һәм зарарлы организмнардан саклау | Җирле бюджет:<br>2021 ел – 900 сум,<br>2022 ел – 900 сум,<br>2023 ел – 900 сум. | Авыл җирлеге башкарма комитеты | 2021-2023 еллар | Башкарма комитет җитәкчесе |

2. Карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Башкарма комитет җитәкчесе С.Д,Инькова